Республика Татарстан
Старо-Имянское сельское
поселение Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль
районынын Иске Имән
авыл жирлеге

КАРАР
25.11.2021

КАРАР
№31

Советның 2017 елның 21 августындагы 59 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясына туры китерү максатларында, Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында 2017 елның 21 августындагы 59 номерлы Совет карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 бүлекнең 7 пунктындагы 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
7)әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы) яисә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;»;

2) 5 бүлекнен 5 пунктындагы 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«9) яллаучы (эш бирүче) вәкиленә Россия Федерациясе гражданлыгын туктату турында яисә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы булган чит ил гражданлыгы (подданствосы) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы, муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көндә, ләкин чит ил

гражданының муниципаль хезмәттә булырга хокукы булган Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданлыгы (подданствосы) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча язма рәвештә хәбәр итәргә;»;

3) 5 бүлекнең 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9.1 пункт өстәргә:
«9.1) чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алган яисә яшәүгә рөхсәт кәгазе яисә гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алган очракта, муниципаль хезмәткәргә бу турыда билгеле булган көнне, әмма чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алынган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, яисә чит дәүләт территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алган көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, яллаучы (эш бирүче) вәкиленә язма рәвештә хәбәр итәргә;»;

4) 5 бүлекнең 7 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату яисә чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәт алу төре яисә чит дәүләт территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу (әлеге Федераль законның 41 статьясы) »;

5) 9 бүлекнең 1 пунктындагы 2 пунктчасын үз көчен югалткан дип таныргa.

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Интернет челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл жирлеге
Советы Рәисе — Р.Ә.Исламова